ПРЕЗИДЕНТТАН – БҮЛӘК

Казан дәүләт аграр университетының «Студентлар йорты»н капиталь ремонттан соң ачтылар

> 2

РАФАЭЛЬ ШӘВӘЛИЕВ:

«Дәва сырхауга вакытында килергә тиеш»

> 3

КӘНФИТ ТҮГЕЛ

Белгечләр белер-белмәс дару эчүчеләрнең артуына борчыла

> 3

ХА-ХА-ХАНӘ

Кызык-мызык, булмас димә, фототөрткеләр – монда

> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 136 (28909) | Шимбә | 17 сентябрь | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Гөлгенә ШИҺАПОВА

ШАУЛА, УРМАН!

18 СЕНТЯБРЬ – УРМАН ХЕЗМӘТКӘРЛӘРЕ КӨНЕ

Бәйрәм көткәндә

Бу якшәмбедә Татарстан урманчылары үзләренең һөнәри бәйрәмнәрен билгеләп үтә. Җәйге эсселәр бетеп, янгын куркынычы кимегән чор, еллык эшкә нәтиҗә ясар вакыт... Алар яз утырткан агачларын көз саный. Бүген урманчылар ничек яши? Эшче куллар җитәме? Татарстан урманнарында нинди проблемалар бар? Бәйрәм алдыннан «ВТ» журналисты шул сораулар белән аларның үзләренә мөрәҗәгать итте.

– Урманга бер керсәң, кире чыгам димә икән, – дип сүзен башлады республика урман янгыннарын сүндерү үзәге җитәкчесе Айдар Гайфуллин. – Без егет чакта «экология», «табигатьне саклау» дигән сүзләр еш ишетелә башлады. Кешедән калышып буламы соң? Мин дә Казанга авыл хуҗалыгы институтының урманчылар әзерли торган факультетына укырга кердем. Баштарак яратып укыдым дия алмыйм. Хәтта практика үткәндә дә, урманда калмам, ахры, дигән идем. Тора-бара фикерем үзгәрде. Урман үзенең матурлыгы, саф һавасы белән җәлеп итте. Миңа хәзер башка эш кирәкми дә.

Шөкер, быел куркыныч янгыннар булмаган. «Берничә тапкыр урманнарга керүне чикләдек. Республикада янгын куркынычы зур булды. Ике ай яңгыр яумавы сак булырга өйрәтте. Әмма урманчыларның көн-төн кизү торуы, тирә-якка битараф булмавы аркасында, без җәйне югалтуларсыз чыктык. Әлегә артык сөенеп тә булмый. Янгынга каршы режим 15 октябрьгә кадәр дәвам итә», – диде Айдар.

Аның әйтүенчә, республикада янгынга каршы тору өчен барлык мөмкинлекләр тудырылган. Татарстанның төрле почмакларында урман янгыннарын сүндерү станцияләре эшләп тора. Урманчыларга кирәкле техникалар да бирелгән. Яшьләрне урманга тарту өчен, кулдан килгәннең барысын да эшлиләр. Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов ярдәме белән, эшкә яңа урнашкан яшь белгечләргә бер тапкыр акча бирелә. Лубян урман көллиятен тәмамлаучылар – 150 мең, вузлардан килүчеләр 300 мең сум ала.

Ә менә элек урманчыларга андый мөмкинлек юк иде. Укып бетерәсең дә, кайтасың да эшлисең. «Бөгелмә урманчылыгы» җитәкчесе Гөлнара Мөхәммәтханова да нәкъ шулай эшләгән.

– Мәктәпне бетергәч, бер балл җитмичә, институтка керә алмадым. Озак уйлап тормадым, авылыбыздан ерак булмаган Лубян көллиятенә укырга кердем. Бу адымыма бер дә үкенгәнем булмады. Үз эшемне яратып башкарам. Башта урманда 14 ел мастер булып эшләдем, аннары инженер, 2012 елда җитәкче итеп куйдылар. Элеккеге белән бүгенгене чагыштырып та булмый. Кул хезмәте кимеде.

сохраанимлес.рф

Техникаларның иң яхшыларын кайтаралар, хезмәт хакларыбыз артты. Агачлар яхшы үссә, утыртканы корымаса, аларда авырулар булмаса, сөенеп кенә эшләрлек, – ди ул.

Авыру дигәннән, Татарстан урманнарында төрле чирләр очрый. Нурлат урманчылыгы җитәкчесе Рөстәм Галиев быел урманда агачларны ефәк күбәләк корты басып алуын әйтә.

– Июль аенда агач яфракларын ашап бетерделәр. Алардан кортлар күбәләккә әйләнгәч кенә котылдык. Очып китүгә, агач яфраклары яңадан чыкты. Әмма әле борчылып торабыз. Кортлар йомырка салып калдырмадымы икән, дибез. Тагын бер кат бөтен агачларны тикшереп чыгачакбыз. Әгәр йомыркалары булса, язын агачларны махсус дарулар белән эшкәртмичә булмый, – ди ул.

Нурлат урманчылыгында коллективта яшьләр шактый икән. Яңа гына укып бетергән егетләр дә кайткан үзләренә. Тагын бишесе Лубянда белем ала, укып бетергәч кайтачаклар. Җитәкченең киләчәк өчен күңеле тыныч.

– Кайчандыр мин дә шул егетләр яшендә урманга килдем инде. Табигатьне ярату үзенекен эшләде. Монда гаилә кордым, йорт салдым. Шәһәргә китү уемда да булмады, – ди ул.– Эшлим дигән кешегә урманда да эш җитәрлек. Безнең максат – урманнарны арттыру, ел саен күпләп агач утыртабыз.

Татарстан урман хуҗалыгы министры Равил Кузюров сүзләренә караганда, республикада 3,6 мең гектар җирдә урман утыртылган.

– Әлеге эшләр «Экология» илкүләм проекты кысасында «Татарстанда урманнарны саклау» төбәк проекты аша тормышка ашырыла. Бу проект күп кенә эшләрдә ярдәм итә. Урманчылык һәм урман оешмаларының техника паркын яңарту, урманнарны янгыннардан саклау һәм яңадан торгызу эшләре – барысы да шулар ярдәме белән башкарыла, – диде министр.

Быел 15 сентябрьгә урманчылыкларда 1232 килограмм орлык әзерләнгән. Орлык җыю эше октябрь башына кадәр дәвам итәчәк.

– Урман утырту чималына кытлык юк. Без 51 питомникта кәлшә үстерәбез. Саба орлыкчылык үзәгендә ел саен ябык тамырлы 12 миллион данә үсенте җитештерелә. Табигатьне саклау акцияләре ярдәмендә ел саен күпләп агач утыртыла, урманнар чүп-чардан арындырыла, – ди министр. – Заман белән бергә атларга тырышабыз. Соңгы өч елда урман фондының бердәм мәгълүмати системасын булдырдык. Быел урман хуҗалыгында 13 хезмәт электронлашты. Хәзер урман җирләрен арендага, агачларны сатып алырга теләүчеләр ул эшләрне Дәүләт хезмәтләре порталы аша да башкара алачак.

Кредитлар арзаная

Россия Үзәк банкы, төп ставканы 0,5 пунктка киметеп, 7,5 процентка калдырган. Моңа кадәр бу күрсәткеч 8% иде. Димәк, кредитлар һәм депозитлар ставкасы берникадәр кимеячәк, дигән сүз. «Хәзер бәяләр нык үсми, шуңа күрә инфляция дә акрыная. Бу төрле факторларга, шул исәптән кулланучылар ихтыяҗы кимүгә бәйле. Эш активлыгы – Россия банкы күздә тотканнан яхшырак. Әмма Россия икътисады өчен тышкы шартлар катлаулы булып кала һәм, элеккечә үк, икътисади эшчәнлекне чикли», – дип хәбәр итә Үзәк банкның матбугат хезмәте.

Сентябрь аенда еллык инфляция 14,1% (июль аенда 15,1% иде) тәшкил иткән.

Март аенда бәяләр кискен күтәрелеп алганнан соң, хәзерге вакытта төшүен дәвам итә. Үзәк банк фаразына караганда, агымдагы ел азагына инфляция 11–13 процентка калачак, 2023 елда 5–7% тәшкил итәчәк, ә инде 2024 елда максатчан күрсәткечкә – 4 процентка кире кайтачак.

Бәяләр йөгәнләнде

Республикада помидор, кәнфит, балалар өчен ит консервлары, тары ярмасы бәясе төшкән. Шулай ук шоколад кәнфитләр, кайбер башка продуктлар да арзанайган. Татарстанстат мәгълүматлары буенча, бер атна эчендә помидор бигрәк тә нык очсызланган (2,94%). Хәзер аның килосы 62,2 сум тәшкил итә. Шоколад кәнфитләр бәясе исә 2,33 процентка төшкән: уртача хакы 395,56 сум тәшкил итә. Тары – 2,19 процентка (килосы – 43,95 сум), балалар өчен ит консервлары 2,72 процентка (килосы – 914,42 сум) арзанайган.

Республикада шулай ук сарык, дуңгыз ите, сосиска һәм сарделька, атланмай, үсемлек мае, сөт, эремчек, балалар өчен җиләк-җимеш консервлары бәясе кимегән. Моннан тыш шикәр комы, тоз, бодай оны, алма һәм банан очсызланган.

Үсеш нокталары

Быел республика авыллары һәм кечкенә шәһәрләре мәктәпләрендә 117 «Үсеш ноктасы» үзәге ачылган. Табигать фәннәре юнәлешендәге һәм технологик юнәлештәге үзәкләр бу. Мәгариф һәм фән министрлыгы хәбәренә караганда, биредә укучылар һәм укытучылар сыйныфтан тыш эшләр, бәйгеләр оештыра, проект эшчәнлеге белән шөгыльләнә ала. Хәзер үзәкләрдә физика, химия, биология фәннәрен үзләштерү өчен бөтен мөмкинлекләр бар. Дәресләрдә заманча җиһазлар ярдәмендә тәҗрибәләр һәм сынаулар үткәрергә, шулай ук өстәмә белем бирү программалары буенча эшләргә мөмкин.

COVID-19

Меңгә ерак калмады

Татарстанда узган тәүлектә коронавирус инфекциясен 998 кеше йоктырган. Шунысы да бар: авыручыларның 98 проценты чирне җиңел, кискен билгеләрсез генә уздыра. Шулай да җиңел дип кенә чирдән котылмадык әле. Белгечләр республикадагы вазгыятькә бәя бирде.

Роспотребнадзорның Татарстан буенча идарәсе башлыгы урынбасары Любовь Авдонина сүзләренә караганда, авыручылар саны бер меңгә якынлашса да, республикада өстәмә чикләү чаралары кертергә җыенмыйлар. Киңәш буларак тәкъдим ителгәннәре дә, гамәлдә булган чаралар да вазгыятьне кулдан ычкындырмаска мөмкинлек бирә.

Моннан тыш республикада кискен респиратор вируслы инфекцияләр белән чирләүчеләр дә арткан. «19 процентка арту күзәтелә. Бу – көтелгән, сезонлы күтәрелеш. Грипп очраклары юк. Хәзер гриппка һәм коронавируска каршы вакцина ясату өчен менә дигән вакыт. Грипп очраклары, гадәттә, октябрь урталарында, ноябрь аенда теркәлә башлый», – дип аңлатты Любовь Авдонина.

Вакцинациягә бәйле санлы мәгълүматларны Татарстанның сәламәтлек саклау министры урынбасары Владимир Жаворонков җиткерде. Белгеч әйтүенчә, хәзерге

Илдар Мөхәммәтҗанов

көндә Татарстанда коронавируска каршы вакцинаның беренче компонентын 2734119 кеше алган. Ревакцинацияне 1,45 млн кеше узарга тиеш. Гомумән алганда, прививка ясату кампаниясе башланганнан бирле республикага 3271353 доза коронавируска каршы вакцина кайтарылган.

Сүз уңаеннан, Татарстанда балалар өчен «Спутник М» вакцинасының 75 проценты кулланылган. Владимир Жаворонков әйтүенчә, 12–17 яшьлекләр өчен 8720 доза вакцина кайтартылган иде. Республикада бу яшь аралыгындагы 193 меңләп бала яши.

Вакцинация күрсәткечләре белгечләрне канәгатьләндерми. Моңа карамастан, мобиль вакцинация пунктларын арттыру нияте юк. Хәер, моңа ихтыяҗ да сизелми.

Владимир Жаворонков сүзләренчә, Казанда коронавируска каршы прививканы тәүлекнең теләсә кайсы вакытында ясатырга мөмкинлек бар. «Минемчә, без – Россиядә бердәнбер шундый төбәктер. Вакцина ясатырга килсеннәр генә. 7 нче шәһәр хастаханәсендә тәүлек буе кабул итәләр», – дип искәртте белгеч.

САН

«Стопкоронавирус.рф» сайты китергән мәгълүматларга караганда, Россиядә узган тәүлектә 59035 кеше коронавирус йоктырган. 110 кеше үлгән. 4178 кешене хастаханәгә салганнар. 50 меңнән артык кеше чирдән дәваланып чыккан.

Сүзгә-сүз

Динар СӘМИГУЛЛИН, Татарстанның цифрлы трансформация үзәге директоры:

Ничек кенә булмасын, цифрлаштыру яшәешебезнең барлык тармакларына да үтеп керде һәм без моңа ияләнеп киләбез. Ләкин цифрлаштыруга ышанмаган кешеләр дә бар һәм булачак. Бу – нормаль күренеш. Без ирекле илдә яшибез, бүген һәркем үзенә уңайлы булганны сайлый ала. Әйтик, үсеп килүче буынның ихтыяҗлары бөтенләй башка төрле. Алар башкача фикерли. Һәм аларның электрон серверларга мөнәсәбәте дә башка төрле.

(«Татар-информ»)

ҖӘЙГЕ ЯЛ НӘТИҖӘЛӘРЕ

Илкүләм җәмәгатьчелек фикерен өйрәнү белгечләре Россиядә яшәүчеләрдән җәйге ялны ничек үткәрүләре турында сорашкан.

2% >> чит илдә ял иткән

28% >> бакчада ял иткән

33% >> ялын өй мәшәкатьләре белән уздырган

35% >> ялны хыялланганча уздыра алмаган

Шимбә – ярминкә көне

Бүген Казанда ярминкә уза. Анда 22 район фермеры һәм 18 агросәнәгать оешмасы үз продукциясен алып килгән. Ярминкә иртәнге 6дан көндезге 12гә кадәр 15 сәүдә мәйданчыгында гөрли. Казан мэриясе матбугат хезмәтеннән хәбәр ителгәнчә, анда чагыштырмача арзан бәядән сыйфатлы яшелчә, ит ризыклары, шулай ук йорт хуҗалыгы, бакча өчен кирәк-ярак сатып алу мөмкинлеге бар. Сәүдә башкалабызның барлык районнарында оештырылган.

Быел көзге ярминкәләр 10 сентябрьдә башланды. Алар 24 декабрьгә кадәр дәвам итәчәк.

ҖИДЕНЧЕ КАТТАН КАРАШ

Наил ШӘРИФУЛЛИН

Җирлеләр ник «чирле»?

Берләшкән Милләтләр Оешмасы моннан 15 ел элек – 2007 елның сентябрендә «Җирле халыкларның хокуклар декларациясе» («Декларация прав коренных народов») дип аталган, үз тарихи җирләрендә гомер сөргән, тик дәүләтчелеге булмау яки аны югалту сәбәпле, башкалар кулына калган азчылык халык һәм милләтләрнең хокукларын яклаган документ кабул итте.

Кабул итү шуннан: дәүләтсез халыклар хәтсез очракларда, үз язмышларына хуҗа булмау аркасында, пассионарлыгын, башкача әйткәндә, яшәү көчен, сәламәтлеген, телен, мәдәниятен, гореф-гадәтләрен акрынлап югалтуга, ягъни дәвамлы «чир»гә һәм, ахыр килеп, инкыйразга дучар ителгән. БМО масштабында моны аңлау бар, әмма аерым дәүләтләр дигәндә, аларның сирәге генә азчылыкларның хокукларын яклау-саклау ягында. Олы милләтләр эгоизмы – вак халыклар югала баруның төп сәбәбе, дисәк тә ялгышмабыз.

Декларацияне дөньяның 143 иле баштан ук хуплап чыкса, 4 дәүләт – АКШ, Канада, Австралия, Яңа Зеландиянең беренче мәлне аның белән килешмәгәнлеге мәгълүм. 11 ил, шул исәптән Россия дә, бер якка да тавыш бирмичә, битараф калган. Ләкин әлеге мөһим документ кабул ителеп, берничә ел узуга, Канада, Австралия һәм Яңа Зеландиянең Декларациягә мөнәсәбәте капма-каршы якка, башкача әйткәндә, яхшыга үзгәрә. Ул гына да түгел, саналган өч илнең беренче икесе үз җирләрендә яшәгән азчылык халыклардан элекке чорлардагы хаталары, кылынган җинаятьләре өчен рәсми төстә гафу да үтенгән. Ә бит чынлыкта өч ил түгел, кимендә өч дистә ил гафу үтенергә тиеш иде. Үтенмәделәр, димәк, җәбер кайда ачыктан-ачык, кайда астыртын дәвам итәчәк.

Декларациянең асылы иң вак халыкларның да телләрен, гореф-гадәтләрен, мәдәниятләрен кадерләп саклау, шуңа мөмкинлекләр тудыру, дәүләтчелеге, үзләрен яклар институтлары булмаганнарга киң хокуклар бирү мөһимлеген ассызыклауга кайтып кала. Ул телләр, ул культураларның, иң күп кулланышлы телләр, мәдәниятләр белән беррәттән, кешелек дөньясының мәдәни байлыгы, үткәннәрдән калган рухи мирас икәнлеге әйтелә. Бер генә телнең кулланылмый башлавы, гореф-гадәтләрнең юкка чыгуы кешелек өчен кире кайтмаячак югалту, рухи ярлылану икәнлеге белдерелә. Бу чыннан да шулай. Бер генә төр үсемлек йә җанвар юкка чыгу да флора һәм фаунаның бер баскычка фәкыйрьләнүен аңлаткан кебек, иң кечкенә халыкның бетүе дә – зур югалту. Флора, фауна, дигәндә, Кызыл китаплар, тыюлыклар, кануннар бар. Тик менә, халыклар, дигәндә…

Язуларынча, Россия киңлекләрендә 190лап халык һәм милләт яши. Шуның 100дән артыгы – җирле халыклар. Ягъни гомер-гомергә үз тарихи туфрагында көн күргән, каядыр китәр җире, сыеныр почмагы, читтә ватаны булмаган азчылыклар. Шунысын да искәртик: йөзнең яртысыннан күбесе, төгәлрәге, алты дистәләп халыкның исәбе-саны 50 меңгә дә тулмый. Андыйларны кызганырга гына кала. Илдә милли сәясәт үзгәрмәгәндә, иселе телгә алынган Декларация ратификация узып, аның төп параграфлары берәр хикмәт белән биредә закон көчен алмаганда, болар – тулысынча үзләрен җуячак һәм инде җуйган кавемнәр.

Кызыксынган кеше Россиядәге азчылыклардан бары дүрт милләт ул һәм кызларының гына (татар, башкорт, чуаш, чечен) саны миллионнан артып китүен белә. Калган 30–35 милләт һәм халыкта андый ишлелек юк. Аларның саны – 50 мең белән 500 мең арасында. Мондый күренеш тә бер тел, бер мәдәният, дип йөрүчеләр бәхетенә. Чөнки ассимиляция шартларында халык никадәр аз санлы булса, ул шулкадәр тизрәк «эри», эре халыклар өчен ашламага әйләнә.

Әйткән-әйткән, биредә яшәгән ике дистә «ыру»ның, ассимиляция дигәндә, башкалардан өстенлекле икәнен дә билгеләми ярамас. Болар – читтә ватаннары булып та, язмыш ерак бабаларын кайчандыр Россиягә ташлаган, нәсел-нәсәбенә инкыйраз янамаган кайгысызлар. Шул ук кореялы, алман, казах, украин, молдован һ.б. Биредә нидер ошамаса, яисә кыерсыта, кага башласалар, алар теләсә кайчан тәртәләрен үз ватаннары ягына бора, иленә кайтып китә ала. Чикләр ачык. Җирле халыкларның барыр җире юк. Аларның ике генә юл: йә карагруһчыларга, ассимиляция тарафдарларына үч итеп, исән калу, яисә җәһәннәмгә китеп югалу…

Без яшәгән илнең Төп Законы «Без – Россия Федерациясенең күпмилләтле халкы…» дип башлана. Матур сүзләр. Төп Законга үзгәрешләр кертелгәннән соң, преамбуладагы ул сүзләр сакланган тәкъдирдә дә, дәүләт төзүче булып бер генә халык калды. БМО ерак, ул якын очракта да аның Декларацияләрен үтәүне беркем дә мәҗбүр итә алмый. Үзебезнең Төп Закон тиешенчә үтәлсен иде, диясе генә кала. Конституциянең 69 нчы маддәсендә: «Дәүләт азчылык халыкларның хокукларын халыкара хокук нормалары нигезендә гарантияли», – дип язылган. Язылган, ләкин менә үз ана телендә имтихан бирергә дә хокукы юк…

Сорау туа: каян килгән тар күңеллелек соң бу? Ни өчен кайберәүләр безнең киләчәк, исәнлек ягында түгел? Ихтимал эрү-югалуга киртә куярга тырышмау нигезендә сепаратизмнан, төрле үзбилгеләнешләрдән курку, шик ятадыр. 1990 елларда, мәсәлән, шул ук чеченнар «башка чыгарга» бик теләде, теләкләрендә шактый ерак китеп, кан коюга тикле барып җиттеләр. Татарстан башка юлны сайлады. Тик без омтылган икътисади мөстәкыйльлек, милли үзаңны күтәрүгә юнәлтелгән гамәлләребез дә кайберәүләрне хафага салды. Күңел тарлыгының икенче сәбәбе – янәсе, ил бер милләт вәкилләреннән торганда гына бердәм, көчле була. Ассимиляция шул ягы белән «яхшы»: ул милли үзаңны, кешенең үзен тегe яки бу халык вәкиле итеп тоюын (идентичность) юкка чыгара. Шаукым яклылар аны беренче чиратта яшь буынга юнәлтә. Шул ук мәгариф системасына. Фәннәрне татарча укытмауның беренче нәтиҗәләрен инде күрәбез: татар авылларында балалар русча аралаша башлады. Татарны ничә гасыр буе исән тотып килгән галиҗәнап татар авылында татар мохите кысрыклану – үтә дә хәтәр симптом…

БМО кабул иткән актларны бар тарафларда да төгәл үтәү, җиренә җиткерү механизмы булдырылсын иде. Карарлар теләкләр декларациясе булып калмаган чакта гына кече халыклар исәнлеге гарантияләнәчәк, олы милләтләр китергән чир чигенәчәк.

РӨСТӘМ МИҢНЕХАНОВ:

«МОНДА УКУЫМ БЕЛӘН ГОРУРЛАНАМ»

«Татар-информ»

Казан дәүләт аграр университеты оешуга быел 100 ел тулды. Шушы вакыт эчендә уку йорты авыл һәм урман хуҗалыгы өчен 40 меңнән артык белгеч әзерләгән. Алар арасында агроном, инженер-механик, икътисадчылар да бар. Юбилей уңаеннан Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов үзе укыган вузда һәм тулай торакта кунакта булды.

Президент башта капиталь ремонттан соң үзе яшәгән тулай торакны ачу тантанасында катнашты. Ул заманча 9 мең квадрат метр мәйданны биләгән ике бинаны берләштерә. Монда 800 студент яшәячәк.

– Тулай торак бик матур килеп чыккан, «Ферма»ны танып та булмый хәзер. Укыганда мин дә шушында яшәдем. Дәресләрнең күбесе Карл Маркс урамында урнашкан бинада узды. Ә иң кәттә студентлар шушы беренче комплекста яшәде, – диде Президент, студент елларын искә төшереп. – Уку йорты оешуга 100 ел тулу уңаеннан, вуз өчен нәрсә булса да эшләү теләге бар иде. Безгә сыйфатлы белем генә түгел, студентларга яшәү өчен уңай шартлар тудыру да мөһим. Студентларга укуда уңышлар телим, агросәнәгать белем бирү системасына алга таба да булышырбыз. Хәерле сәгатьтә!

Тулай торак түгел, «Студентлар йорты» дип йөртәчәкбез! Казан дәүләт аграр университеты ректоры Айрат Вәлиев әнә шулай диде. «Бу вакыйгага студентлар да, әтиәниләр дә сөенә. Монда барлык факультетларның студентлары яшәячәк», – диде ректор һәм әлеге бүләк өчен Президентка рәхмәтен белдерде.

Чарада Россия аграр вузлары берләшмәсенең генераль директоры Виктор Бердышев та чыгыш ясады. Аның әйтүенчә, Татарстанда аграр вузга мөнәсәбәт илнең барлык төбәк җитәкчеләре өчен дә үрнәк булып тора. «Әлеге урынны мин 1992 елдан бирле беләм, монда барысы да яңартылган», – диде Виктор Бердышев.

Президент шул ук мәйданчыкта авыл мәктәпләре һәм кече шәһәрләр өчен оештырылган бөтенроссия АгроНТИ-2022 бәйгесе финалистларын сәламләде. Без ул арада студентлардан яшәү шартлары, уку өчен мөмкинлекләр турында сораштык.

– Тулай торакта аерма – җир белән күк арасы. Элек бар нәрсә иске иде. Хәзер аннан чыгасы да килми, – ди Арча районының Наласа авылы егете Булат Хөсәенов.

Өченче курс студенты Булат Хөсәенов агроинженерия факультетының электр җиһазлары юнәлешендә белем ала. Теләге – укып бетергәч, авылына кайтып хезмәт итү. «Күңелем авылга тарта. Безнең авылдан тагын ике егет бар әле. Алар да кире кайтачак. Барыбыз да авылны күтәрү өчен тырышачакбыз», – ди Наласа егете.

Ә менә Казахстаннан килгән Дмитрий Пахота башкача уйлый. Беренче курс студентының башкаланың һәр сукмагына, һәр үзенчәлекле архитектурага сокланып йөргән чагы. Булачак эколог ул. Шуңа күрә шәһәрнең ничек яшелләндерелүе дә аңа бик кызык. «Казанны бер күрүдә яраттым, киләчәктә монда яшәргә калырга телим», – ди Дмитрий.

Соңыннан тантана Карл Маркс урамында урнашкан төп уку бинасында дәвам итте. Монда Президент вузның юбилее уңаеннан алдынгы мөгаллимнәргә Дәүләт бүләкләре тапшырды. Фәндәге казанышлары һәм югары квалификацияле белгечләр әзерләве өчен университет коллективы «Татарстан алдындагы казанышлар өчен» ордены белән бүләкләнде.

– Нәкъ менә монда белем алуым белән горурланам. Университет дипломы һәрвакыт сыйфат билгесе булды. Киләчәктә дә шулай булыр дип ышанам. Безгә тормышка хәер-фатыйха биргән остазларыма рәхмәт, – диде Рөстәм Миңнеханов. – Университет агросәнәгать тармагында яңа технологияләр кертүдә инновацион үзәк булып тора. Аның актив рәвештә үсүе сөендерә: югары уку йорты базасында белем бирү оешмалары һәм бизнес-бергәлекләрнең инновацион моделе тормышка ашырыла. Вузга студентлар санын арттыру бурычы куелган.

Быел Казан дәүләт аграр университеты илнең 54 вузы арасында 13 нче урынга чыккан. Бүген вузда 4,6 меңнән артык студент һәм аспирант укый, шуларның 120се – чит ил вәкилләре. Абитуриентларның 80 проценты – авыл балалары. Уку йортын тәмамлаучылар арасында Татарстан Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев, Президент Рөстәм Миңнеханов, финанс министры Радик Гайзатуллин һәм башкалар бар.

Сәрия МИФТАХОВА

ПРЕЗИДЕНТ КӨНДӘЛЕГЕ

Халыкка – ишегалды, яхшы эшләр өчен – машина. Татарстан Президенты кичә Казандагы төзекләндерелгән яңа урыннар белән танышты.

Республика Президенты һәм шәһәр мэры Совет районындагы төзекләндерелгән дүрт ишегалдында башкарылган эшләр белән танышты. Биредә «Безнең ишегалды» республика программасы кысасында шактый эш башкарылган. Төзекләндерелгән территория Кирпичников, Попов, Пионерлар һәм Журналистлар урамнарындагы 15 күпфатирлы йортны үз эченә ала. Биредә 2 меңгә якын кеше яши.

Рөстәм Миңнеханов ял итү зоналарын, балалар уен мәйданчыгын карады, биредә яшәүчеләр белән аралашты.

Моннан тыш Татарстан Президенты Сеченов урамында урнашкан «Игелекле Казан» коворкинг үзәгендә дә (эш һәм ял өчен заманча урын) булды. Төзекләндерелгән бинада колл-үзәк, конференцияләр залы бар, ул 100ләп хәйрия берләшмәсен үз эченә ала. Хәзер бу киңлектә остаханәләр оештырырга, семинар, дәресләр бирергә, волонтерларны укытырга, башка төрле чаралар үткәрергә дә мөмкинлек бар. Коворкинг үзәгендә сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикле балалары булган әниләр дә үзләренә урын таба ала.

Очрашуда Татарстан Президенты «Игелекле Казан» җәмгыяте директоры Татьяна Мерзляковага «Лада Ларгус» автомобиленә сертификат тапшырды. Машинаны арбада хәрәкәтләнүчеләрне йөртү өчен кулланачаклар.

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ УКАЗЫ

«Татэнерго» акционер җәмгыятенә һәм «Элекон заводы» акционер җәмгыятенә «Хезмәт батырлыгы предприятиесе. 1941–1945 еллар» республика исеме бирү турында

1941–1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңү яулауга зур өлеш керткәннәре, Бөек Ватан сугышы елларында хәрби һәм граждан продукциясен өзлексез җитештерүне тәэмин иткән сәнәгать предприятиеләре хезмәткәрләренең массакүләм хезмәт каһарманлыгы һәм фидакарьлеге өчен «Татэнерго» акционер җәмгыятенә һәм «Элекон заводы» акционер җәмгыятенә «Хезмәт батырлыгы предприятиесе. 1941–1945 еллар» республика исеме бирергә.

Татарстан Республикасы Президенты Р.Н.Миңнеханов

Казан, Кремль. 2022 ел, 15 сентябрь
№ ПУ-644

УРМАНЧЫНЫ ОЛЫЛАП

Урман хезмәткәрләре көне уңаеннан тармак хезмәткәрләре һәм ветераннарын республиканың урман хуҗалыгы министры Равил КУЗЮРОВ котлады

«Урман җирдәге иң мөһим табигый ресурсларның берсе булды һәм шулай булып калачак та. Киләчәк буыннар өчен урман байлыкларын саклау һәм арттыру, аларны нәтиҗәле һәм сакчыл куллануны тәэмин итү, илнең экологик куркынычсызлыгын ныгыту – һәммәбез өчен дә уртак бурыч. Безнең эшебез нәкъ шул кыйммәтләргә нигезләнә дә инде, – диелә котлау хәбәрендә. – Татарстан Республикасының урман хуҗалыгы – динамикалы рәвештә үсә торган өлкә. Төбәктә урманнарны саклау, яклау һәм яңадан торгызу буенча максатчан эш алып барыла, тармак оешмаларының матди-техник базасы яңартыла, эшчәнлеккә инновацияләр һәм фәнни казанышлар кертелә. Соңгы елларда цифрлы технологияләр өлкәсендә алга китеш булды – урман хуҗалыгын идарә итүнең нәтиҗәлелеген арттырырга мөмкинлек бирүче берничә система һәм сервис эшләнде. Әлбәттә, югары нәтиҗәләргә күп очракта Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Нургали улы Миңнеханов һәм Урман хуҗалыгы федераль агентлыгы ярдәме белән ирешелде.

Республиканың урман хуҗалыгында югары квалификацияле белгечләр, үз эшләрен белүче һәм ихлас яратып башкаручы кешеләр эшли. Югары профессиональлек, җаваплылык һәм үз эшегезгә бирелгәнлек – һәрберегезне характерлый һәм төбәкнең социаль-икътисади потенциалын ныгытырга мөмкинлек бирә торган үзенчәлекләр. Республиканың урман хуҗалыгын үстерүгә керткән тырыш, фидакарь хезмәтегез һәм бәяләп бетергесез өлешегез өчен чын күңелдән рәхмәт белдерәм».

БЕЗНЕҢ ЗАМАН ГЕРОЙЛАРЫ

КАЗАНДА «ДОБРО» БӨТЕНРОССИЯ КОНФЕРЕНЦИЯСЕ УЗА

15–17 сентябрьдә Казанда «Добро» Бөтенроссия конференциясе уза. Анда илнең 82 төбәгеннән волонтерлык хәрәкәтенең 500 лидеры җыелды.

minmol.tatarstan.ru

Конференция волонтерлар хәрәкәте вәкилләрен, дәүләт учреждениеләрен, уку йортларын һәм башка оешмаларны берләштерде. Ул волонтерлар берләшмәләренең бердәм системасын булдыруны, волонтерлыкның иң яхшы тәҗрибәләрен тарату максатын күз алдында тота. Чара ачылышында катнашучыларны Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин сәламләде.

– Илнең иң яхшы волонтерлык хәрәкәтен оештыручыларның Казанда җыелуына без бик шат. Республикада яшь буынга ярдәм итүгә һәм аларны тәрбияләүгә зур игътибар бирәбез. Игелекле эшләрдә волонтерлар алдынгылар рәтендә тора. Нинди генә авыр вакыт булмасын, алар һәрвакыт кешеләргә ярдәм күрсәтергә әзер. Волонтерлык – ике як өчен дә кирәкле эш. Мохтаҗларга ярдәм күрсәтү аша алар үзләре рухи тәрбия ала. Коронавирус пандемиясе бездә кайгыртучанлыкны арттырды. Волонтерлар саны сизелерлек артты, алар үз теләкләре белән иҗтимагый оешмаларга кушылды. Үзегез өчен, халык, җәмгыять өчен зур эшләр эшләвегезне дәвам иттерегез, – диде Фәрит Мөхәммәтшин.

Дәүләт Думасы Яшьләр сәясәте комитеты рәисе, Волонтерлык үзәкләре ассоциациясе советы һәм «ДОБРО.РФ» платформасы җитәкчесе Артем Метелев конференциягә төрле оешмалардан 1200дән артык гариза килүен әйтте.

– Бу – без башлаган эшкә ихтыяҗ бар дигән сүз. Бүген монда башка кешеләрнең проблемаларына битараф булмаган, аларны хәл итүдә үз өсләренә җаваплылык алган кешеләр җыелды. Әлеге конференциягә килгән 500 оешма алдында үзләренең шәһәрләрендә иҗтимагый үсеш үзәкләрен ачу бурычы тора. Бу – илебезне, гражданлык җәмгыятебезне яхшырту нигезе, – диде ул.

Артем Метелев әйтүенчә, соңгы тугыз елда илдә социаль проектларда катнашучы гражданнарның өлеше арткан:

– Бу бик мөһим. Бүген без җәмгыятьнең волонтерларын заманыбыз геройлары итеп кабул итүен күрәбез. Бу тема социаль яктан хуплана. Кешеләр волонтерлык оешмаларына ышана, алардан катлаулы һәм тыныч вакытларда да ярдәм көтә. Елдан-ел волонтерлык хәрәкәтенә кызыксыну артуы безне бик сөендерә. Безнең бурыч – волонтерлар өчен яхшы шартлар тудыру, аларга мөмкинлекләр ачу. Игелек кылырга теләгән һәр кеше моны эшли алырга тиеш, – диде ул журналистларга.

Әлеге үзәккә ярдәмгә мохтаҗлар да, үз проектлары булган активистлар да мөрәҗәгать итә алачак. Моның турында Татарстан яшьләр эшләре министры Тимур Сөләйманов әйтте. «Конференция волонтерлык үзәкләре, мәгариф һәм башка оешмалар үзара хезмәттәшлек итсен, фикер алышсын, ил һәм төбәк ресурсларыннан күбрәк кеше файдалана алсын өчен кирәк», – диде министр.

Ләйсән САФИНА

РЕСПУБЛИКА КЛИНИК ХАСТАХАНӘСЕНЕҢ БАШ ТАБИБЫ РАФАЭЛЬ ШӘВӘЛИЕВ:

«ҺӘРКЕМ ҮЗЕН САКЛАРГА ӨЙРӘНСЕН ИДЕ»

Зыян салма! Табибларның төп кагыйдәсе саналган бу сүзләрне табиб булмаганнар кайчан аңлар икән? Адым саен бар өлкәдә дә «белгеч» саналганнар очрап торган чорда яшибез бит. Тән саулыгы белән җан саулыгы бер-берсенә ничек бәйле? Медицинада «куркынычсызлык» дигән төшенчә ни дәрәҗәдә мөһим?

Шулар хакында Республика клиник хастаханәсе баш табибы Рафаэль ШӘВӘЛИЕВ белән сөйләштек.

rkbrt.ru

:: Рафаэль Фирнаялович, очрашуыбыз ел саен 17 сентябрьдә үткәрелә торган Бөтендөнья пациентлар куркынычсызлыгы көненә дә туры килде. Шулай булгач, сөйләшүебезне «Медицина ярдәменең куркынычсыз булуы нәрсәгә бәйле?» дигән сораудан башласак, дөресрәк булыр.

– Куркынычсызлык – иң кирәкле сыйфат. Сырхау кеше өчен бигрәк тә. Юл мисалында карыйк. Юл хәрәкәте кагыйдәсен бозасыңмы син, юкмы – һәлакәткә эләгәсең икән, ике як та зыян күрә дигән сүз. Медицина тармагында да шул ук хәл. Ул сырхауга да, аның туганнарына да, табибларга да, хастаханә җитәкчелегенә дә, хәтта хакимият вәкилләренә дә, министрга да, тармакка да йогынты ясый. Нindидер куркыныч һәлакәт, нindидер гадәттән тыш хәл килеп чыкса, зыянын һәркем күрәчәк.

Дөрестән дә, 17 сентябрьдә Халыкара пациентлар куркынычсызлыгы көне билгеләп үтелә. Быел ул «Зарарсыз дару» девизы астында уза. Ни өчен шулай? Чөнки коронавирус чорында күпләр үз белдеге белән дәвалана башлады. Барысы да табибка әйләнде. Аннан, медицина тармагында әйләнешкә яңа дарулар да керде. Без, үз чиратыбызда, алар турында аңлатырга тиеш. Аллергия бирәме ул, кешедә башка төрле күренешләр китереп чыгарамы – бар нәрсә дә күз уңында булырга тиеш. Бернәрсәне дә яшереп калырга ярамый. Күп кенә бәлаләр дә әнә шуннан башлана. Форсаттан файдаланып, шуны да әйтәсе килә: табиб дөрес рецепт язып бирсә дә, кеше организмындагы барлык нечкәлекләрне, үзенчәлекләрне белеп бетермәскә мөмкин бит. Аны әйтергә кирәк. Моннан кыенсынмаска иде! Күп сырхаулар бер тапкыр табибка күренә дә, ул язып биргәнне бер тапкыр үти дә: «Бу миңа туры килми, бу табибка башка бармыйм», – дип йөри. Әмма бит киресен эшләргә кирәк! Табибка яңадан барырга, гади итеп әйтсәк, хатаны төзәтергә.

:: Дарулар димәктән, кешеләрнең медицина һәм медицина вәкилләренә ышанычы турында да сүз кузгатыйк әле. Күпләр белгеч сүзенә түгел, интернетта язылганга, кемдер кемгәдер әйткән сүзгә күбрәк ышана бугай. Бу күренешкә сезнең карашыгыз нинди?

– Бу – шактый мөһим сорау. Беләсезме, табиб һәм сырхау арасында иң мөһим сыйфат нәрсә? Ышаныч. Ышаныч булды икән, дәва да булачак. Хәтта җиңә алмаслык авырудан интеккән кеше дә, табиб белән ышанычлы мөнәсәбәттә булса, үз хәлен җиңеләйтәчәк. Киресенчә, җиңелчә генә авырган кеше үзенең сәламәтләнүенә әнә шул ышаныч булмаганга күрә зур киртә куярга мөмкин. Медицина ул дарулар гына түгел әле. Дару ул – химия. Кешенең кәефе дә, халәте дә башка күп факторларга бәйле бит. Ышанычлы мөнәсәбәтләр корылганда да шулай. Психосоматик дәрәҗәдә авыруга уңай йогынты ясала. Организм чир белән системалы рәвештә көрәшә башлый, медикамент исә шул көчне куәтләп кенә җибәрә.

Беләсезме, күп кенә табиблар үзләре, яңа технологияләр турында интернетта нинди мәгълүмат булуы турында кызыксынмый. Ә мәгълүмат кулланучы моны укыйм әле, монысын карыйм әле, дип тормый. Ул мәгълүматны «йота». Блогерларның, «белгеч»ләрнең фикере шуңа да күбрәк, тизрәк тарала.

Минемчә, безнең дә гаеп бар. Тулы ышаныч булсын өчен, безнең дә бу җәһәттән җентекләп эшләвебез кирәк. Аеруча шәфкать туташлары. Иң укымышлы, мәгълүматлы, теләсә кайсы сорауга әзер кеше алар булырга тиеш. Сырхаулар белән бик күп очракта алар күзгә-күз кала. Без хәтта санитар хезмәткәрләрне дә, җыештыручыларны да өйрәтәбез. Кайчагында төннәрен сырхау янында алар гына да калырга мөмкин бит. Ә сораулар булмый калмый. Һәркайсына җавап бирергә әзер булырга тиеш без. Җавап бирү генә түгел, гади итеп аңлату тагын да мөһимрәк әле!

:: Куркынычсызлык кеше факторына гына бәйле түгел. Хәзер медицина тармагына яңа технологияләр җәлеп ителә. Сез җитәкләгән хастаханәдә бу җәһәттән эш ничек оештырылган?

– Дәва сырхауны вакытында табарга тиеш. Әйтик, табиб иртән нindидер дару билгеләгән, әмма аны пациентка кич җиткәндә генә бирәләр икән – бу дөрес түгел. Эшне җайга салуда мәгълүмат технологияләрен кулланырга мөмкин. Татарстанда игълан ителгән Цифрлаштыру елында без хастаханәдә республика Президентының махсус проектын гамәлгә ашырабыз. Ул хастаханәдәге процессларны тулысынча цифрлаштыруга бәйле.

> Республика клиник хастаханәсендә хәзер шулай: табиб күрсәтмәсе шундук шәфкать туташына барып ирешә. Шул ук вакытта теге яисә бу гамәлнең башкарылуы турында хәбәр табибка кайта. Шуңа күрә арада нindидер өзеклек юк. Шул рәвешле пациентның куркынычсызлыгы да тәэмин ителә.

Хастаханәдә билгеле бер дәвалау стандарты булырга тиеш. Без шул юнәлештә эшлибез. Ул эшчәнлекнең, сырхауларны дәвалауның, теге яисә бу хәл килеп чыккан очракта ничек эш итәсен белү өчен, эшчәнлекне өзлексез дәвам иттерү өчен мөһим. Районнарда да шулай булырга тиеш. Шуңа да Республика клиник хастаханәсе базасында Компетенцияләр үзәге эшли. Биредә район үзәк хастаханәләре табибларын билгеле бер система буенча эшләргә өйрәтәбез.

:: Куркынычсызлык дигәндә, хастаханәгә эләккән кешенең туганнары, якыннары турында да әйтмичә булмый. Алар белән элемтә ничек урнаштырыла?

– Мин инде күп еллар эшлим. Без – телефоннар булмаган чордан башлап телефонсыз яшәп булмаган чорга җиткән кешеләр. Хәзерге көндә телефоны булмаган кеше юк. Аны алып куйсаң, кеше чыгырыннан чыга. Элек телефон урынына кеше янында туганы булыр иде. Хастаханәгә яткан кеше турында бөтен туганнары хәбәрдар иде. Ә хәзер... Терелеп чыкканнан соң да белүче юк. Шуңа да якыннар-туганнар белән элемтә булдыру мөһим. Моннан 20 ел элек булган культураны кайтарасы килә. Ягъни туганнар өчен җан атып, кайгырып, хәл белешеп торуны. Без бит хәзер ярдәмне дә, таянычны да күбрәк интернеттан эзлибез. Туганнар белән йә бик авыр, йә бик күңелле сәбәпләр булганда гына күрешәбез. Гел әйтеп киләм: иң ерак туганнарга да көнгә бер булса да шалтыратып алырга кирәк. Әти-әниләргә бигрәк тә. Туган-тумачаларның бер-берләре өчен җан атып торганнарын күрү сөендерә мине. Мин үзем дә тәүлек буе элемтәдә. Миңа авыр түгел. Беләсезме, эш юктан һәм аралашу булмаудан кешеләр күбрәк иза чигә. Активлык һәм аралашу исә рәхәтлек кенә бирә.

:: Укучыларыбызга әйтер сүзегез?

– Төп теләк шул: һәркем үзен сакларга өйрәнсен иде. Тагын юллар мисалында әйтәм инде: беребез дә машина астына махсус ятмый бит. Әмма аңлы рәвештә, ярамаганын белеп, кирәкмәгән дару, сыекчалар кулланабыз. Үз-үзеңне саклаудан тыш, кеше якын-тирәдәгеләргә дә игътибарлы булырга тиеш. Бер кеше үзе үрнәк күрсәтеп, сәламәтлегенә игътибарлы булса, аның тирә-юне дә шул үрнәктә яши башлаячак. Шундый уңай чылбыр барлыкка киләчәк.

Әңгәмәдәш – Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

Кәнфит түгел, дару

Даруны табиб белән киңәшләшкәч кенә эчәсе! Үз белдеге белән дәваланырга яратучыларны белгечләр шулай дип кисәтә. Ник дигәндә, тормышыбызга коронавирус зәхмәте үтеп кергәннән бирле, белер-белмәс дару эчүчеләр саны бермә-бер арткан. Соңгы арада хәтта аз гына авырый башлауга, коронавирус булмагае дип куркып, үз белдеге белән антибиотик эчүчеләр дә күбәйгән. Монысы тагын да хәтәррәк, ди белгечләр. Ник дигәндә, антибиотик – гади генә дару түгел, аны эчкәндә аеруча сак булырга кирәк.

Республика клиник хастаханәсенең клиник фармакологы Альбина Звегинцева сүзләренә караганда, антибиотикларны белер-белмәс кулланган очракта, бактерияләр аның составындагы компонентларга ияләшә, аларга бирешми башлый. «Шул рәвешле иң көчле бактерияләрне дә юк итәргә тиешле антибиотик аларга каршы тора алмый башлый, аның организмга бер файдасы да калмый», – дип сөйләде белгеч журналистлар белән очрашуда.

Моның ни дәрәҗәдә куркыныч икәненә инану өчен, рәсми саннарга күз салу да җитә. Әйтик, 2019 елда антибиотикларга бирешмәс бактерияләр аркасында, дөньяда 6 миллионлап кешенең гомере өзелгән. Чагыштыру өчен: шул ук елны СПИДтан Җир шарында 860 мең кеше үлгән. Галимнәр чаң суга: 2050 елга организмның антибиотикларны кабул итә алмавы аркасында килеп чыккан үлем-китем очраклары кеше гомерен өзгән барлык мәкерле чирләр арасында беренче урынга ук чыгарга мөмкин.

Альбина Звегинцева белдерүенчә, антибиотиклар температураны төшерми, тамак авыртуны да басмый, борынга томау төшүдән дә коткармый. Аларны ОРВИ, грипп кебек вируслы авырулар вакытында да эчәргә ярамый. Антибиотик соңгы арада телдән төшмәгән коронавирустан да дәваламый. Ник дигәндә, алар барысы да – вируслы авырулар. Алар вакытында вируска каршы дарулар эчәргә кирәк. Антибиотиклар исә фәкать бактерияле чирләрдән генә коткара.

– Антибиотикларны, гадәттә, биш көн дәвамында эчәргә кирәк. Чирнең катлаулылыгына карап, табиб аны бер-ике атна дәвамында эчәргә дә кушарга мөмкин. Әмма күпләр өченче көнгә инде үзен яхшы хис итә башлый һәм антибиотиклар эчүне туктата. Артык күп эчсәң, организмга тискәре йогынтысы булыр, дип куркалар. Ләкин бу – зур хата. Болай эшләгәндә, бактерияләр аңа бирешми торганга әйләнәчәк. Шуңа күрә антибиотикларны ничә көн эчәргә кушылган булса, шулай эшләргә кирәк. Антибиотиклар эчәргә тотынгач, хәл яхшыру – аларның файдасы тия башлаган, табиб дөрес дәвалау курсы билгеләгән дигән сүз. Үз белдегең белән антибиотикның дозасын да азайтырга ярамый. Бу шулай ук бактерияләрнең антибиотикларга бирешмәвенә китерәчәк. Аларның дозасын арттырган очракта исә организмга тискәре йогынтысы булырга, кеше агуланырга мөмкин, – ди Альбина Звегинцева.

Антибиотикларны ничек эчәргә?

– Андый даруны табиб кушкан очракта гына эчәргә кирәк.
– Организмның антибиотикларга сизгерлеген тикшерү өчен, алдан бәвел анализы тапшырсаң да яхшы.
– Табиб антибиотикны көнгә ике тапкыр эчәргә кушкан икән, бу аларны иртә-кич кулланырга кирәк дигән сүз түгел. Бер төймәсен эчү белән икенчесе арасында 12 сәгать вакыт узарга тиеш. Көнгә өч тапкыр эчәргә кушылса, аны һәр 8 сәгать саен эчәргә кирәк.
– Даруны чиста су белән эчеп җибәрәсе. Ашар алдыннанмы, ашаганнан соңмы икәне инструкциясендә язылган була.
– Антибиотиклар эчә башлагач, өч көн эчендә хәлегез яхшырмый, организмда уңай үзгәрешләр күзәтелми икән, кабат табибка мөрәҗәгать итәргә кирәк.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ КАРАРЛАРЫ

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының утыз дүртенче утырышын чакыру турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **КАРАР БИРӘ**:

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының утыз дүртенче утырышын 2022 елның 23 сентябрендә 10 сәгатьтә Татарстан Республикасы Дәүләт Советының утырышлар залында чакырырга.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре, 2022 елның 15 сентябре
№ 1550-VI ДС

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының утыз дүртенче утырышы каравына кертелә торган мәсьәләләр турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы **КАРАР БИРӘ**:

Алтынчы чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының утыз дүртенче утырышы каравына түбәндәге мәсьәләләрне кертергә:

1. Татарстан Республикасы җәмәгать судьясын сайлау турында.
2. Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе әгъзаларын билгеләп кую турында.
3. Россия Федерациясе субъектлары – Татарстан Республикасы һәм Марий Эл Республикасы арасындагы чик урнашкан урынны билгеләү турында 2022 елның 12 августындагы 40 номерлы килешүне раслау хакында.
4. «Татарстан Республикасы территориясендә салым салуның патент системасын кертү турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясындагы 1 өлешенең 81 пунктының үз көчен югалтуын тану хакында» 330-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
5. «Татарстан Республикасының аерым закон актларына балигъ булмаганнарга аерым товарлар сатуны чикләүне билгеләү өлешендә үзгәрешләр кертү турында» 312-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
6. «2023 елга Татарстан Республикасында хезмәт базарының төбәк үзенчәлекләрен чагылдыра торган коэффициентны билгеләү турында» 335-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
7. «Салым түләүчеләрнең аерым категорияләре өчен оешмалар табышына салым буенча салым ставкасын билгеләү турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәреш кертү хакында» 324-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
8. «Татарстан Республикасы Бюджет кодексына, «Татарстан Республикасы Бюджет кодексына һәм «Татарстан Республикасы Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы бюджет законнары актларының аерым нигезләмәләренең үз көчләрен югалтуын тану турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәрешләр кертү турында һәм Татарстан Республикасы Бюджет кодексы аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору хакында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәреш кертү турында» 323-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
9. «Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына һәм «Татарстан Республикасының монопрофильле муниципаль берәмлекләре (моношәһәрләре) территорияләрендә төзелгән социаль-икътисадый үсеше алдан билгеләнә торган территорияләр резидентлары өчен оешмалар табышына салым буенча салым ставкасын билгеләү турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 325-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
10. «Татарстан Республикасы Сайлау кодексына һәм Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы аерым закон актларының үз көчләрен югалтуын тану турында» 307-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (II укылыш).
11. «Аерым муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен үзгәртү һәм «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясе чикләре һәм статусы турында» һәм «Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы законнарына үзгәрешләр кертү хакында» 320-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
12. «Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 332-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
13. «Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 14 статьясына үзгәреш кертү хакында» 321-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
14. «Татарстан Республикасында җир асты байлыкларыннан файдалану өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 7 статьясына үзгәреш кертү хакында» 326-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
15. «Янгын куркынычсызлыгы турында» Татарстан Республикасы Законының 4 һәм 19 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 333-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
16. «Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 25 статьясына үзгәреш кертү хакында» 309-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
17. «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 9 статьясына үзгәреш кертү хакында» 319-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
18. «Вөҗдан ирегe турында һәм дини берләшмәләр турында» Татарстан Республикасы Законының 9 һәм 11 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 322-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
19. «Мәгариф турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 327-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
20. «2023 елга Татарстан Республикасында гомуми белем бирү оешмаларында һәм һөнәри белем бирү оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем, шулай ук өстәмә белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен финанс белән тәэмин итү нормативларын раслау турында» 329-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
21. «2023 елга Татарстан Республикасында мәктәпкәчә белемнең уку-укыту программаларын гамәлгә ашыра торган муниципаль мәгариф оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен финанс белән тәэмин итү нормативларын раслау турында» 328-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
22. 2021 елда Татарстан Республикасында мәгарифне үстерү программаларын гамәлгә ашыру барышы турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты доклады.
23. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 8.37 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасы турында.
24. «Коррупциягә каршы көрәш турында» Федераль законның 12.1 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 183172-8 номерлы федераль закон проекты турында (Россия Федерациясе субъектларының дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның хокукый статусын регламентлаштыра торган коррупциягә каршы законнарны камилләштерү өлешендә).
25. «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Оренбург өлкәсе Закон чыгару Собраниесенең закон чыгару инициативасы турында.
26. «Россия Федерациясе Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү турында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Оренбург өлкәсе Закон чыгару Собраниесенең закон чыгару инициативасы хакында.
27. «Хәрби хезмәткәрләр статусы турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында һәм гражданнарның кайбер категорияләрен торак урыннар белән тәэмин итү турында» Федераль законның 3 статьясына үзгәреш кертү хакында» 172859-8 номерлы федераль закон проекты турында (хәрби хезмәттән азат ителгән гражданнарның торак шартларын яхшыртуны тәэмин итү өчен бирелгән федераль бюджет акчаларыннан файдалану нәтиҗәлелеген арттыру максатларында).
28. Хөкүмәт сәгате: «Балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген, сукбайлыгын, хокук бозуларын һәм җәмгыятькә каршы гамәлләрен кисәтү буенча балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау системасы органнары һәм учреждениеләре эшчәнлеге турында».

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре, 2022 елның 15 сентябре
№ 1551-VI ДС

КОТЛЫЙБЫЗ!

Илебезнең мәдәниятен һәм сәнгатен үстерүгә зур өлеш кертүе, күпьеллык нәтиҗәле эшчәнлеге өчен «Казан театр училищесы» (техникумы) дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе укытучысы **Нуриев** Гаптерәүф Салих улына **Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә «Россия Федерациясенең атказанган мәдәният хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

Татарстан Республикасының «Саба өйрәнү-тәҗрибә урман хуҗалыгы» дәүләт бюджет учреждениесе урманчысы **Галимуллин** Раиф Зариф улына, Татарстан Республикасының «Лениногорск урманчылыгы» дәүләт казна учреждениесе участок урманчысы **Ильин** Василий Степановичка, Татарстан Республикасының «Буа урманчылыгы» дәүләт казна учреждениесе җитәкчесе урынбасары-урманчы **Гаффаров** Марат Мөнир улына, Татарстан Республикасының «Зеленодольск урманчылыгы» дәүләт казна учреждениесе Зеленодольск участок урманчылыгы участок урманчысы **Саматов** Әнвәр Әлфәт улына **«Татарстан Республикасының атказанган урманчысы»** дигән мактаулы исем бирелде.

КАЙГЫ УРТАКЛАШУ

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы, беренче чакырылыш (1995–1999 нчы елларда) Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты **ХӨСНЕТДИНОВ Илсур Гайнетдин улының** кинәт вафат булуы сәбәпле, мәрхүмнең гаиләсе һәм якыннарының авыр кайгысын уртаклаша.

ХА-ХА-ХАНӘ

Шушы урында көләсе

Мач әйткән!

САВЕЛИЙ КРАМАРОВ, кино артисты

Мин дуракларны уйныйм, шуңа күрә мине бөтен җирдә туган күрәләр.

ИРЛӘР, ХАТЫННАР һ.Б.

* * *

40 яшь – ир-атлар өчен иң кызыклы вакыт. Кемнеңдер баласы туган. Кемнеңдер – оныгы. Ә кемнеңдер әнисе улына һаман әйбәт хатын эзли.

* * *

– Матурым, син – бу дөньяда минем иң кыйммәтле нәрсәм.
– Җәлләтмә.

* * *

Хастаханәдә язу: «Хатын-кызның ни теләгәнен аңлаган кешеләрне психиатр чиратсыз кабул итә».

* * *

– Лилия, син Марат белән очраша башладыңмы әллә?
– Әйе.
– Хәерче бит ул!
– Аның каравы аның «кредит историясе» яхшы.

* * *

– Күз алдыңа китер. Суда ике ир-ат бата. Берсен син яратсаң, икенчесе сине ярата. Кайсын коткарачаксың?
– Тукта әле, ә нигә ике ир-ат бергә чупылдаша соң анда?

* * *

Ярату авыр түгел. Яратырга лаеклы кешене табу авыр.

* * *

– Мансур! Мин ялгыш кына син качырган акчаларны таптым.
– Вентиляция торбасыннан 3 метрга ничек ялгыш кына мендең?

* * *

– Ой, син – шундый шәп кыз, кемне дә булса бәхетле итәчәксең инде.
– Бәлки, сине?
– Алла сакласын!

АРПАЯЗ КЫЗЫКЛАРЫ

ural-meridian.ru

Фоат ГАЛИМУЛЛИН

Хапиз Фоат

Арпаяз – Кукмара районындагы авыл. Авылда һәркемнең кушаматы була. Мине «Хапиз Фоат» дип йөртәләр иде. Ни өченме? Авылыбызда Хафиз исемле бер абзый бар иде. Башыннан эшләпәсе төшмәде. Яшел эшләпәле Хафиз. Көннәрдән беркөнне Сәрби әбием миңа да – алты-җиде яшьлек малайга – Пүләнкә базарыннан эшләпә алып кайтты. Яшел төстә. Шуны киеп, урамга чыгуым булды, Варакыяттәнең Билалетдине очрады. Аңа бир инде кешегә үчек тагарга. Күзенең кырые белән генә карап алды да: «Ә-ә, Хапиз», – дип куйды. Авылдагы өч Фоаттан мине аеру өчен ябышты да калды шушы кушамат.

Әти күрми

Илленче елларда, чыпчык тезеннән булса да, авылыбызда инеш бар иде әле. Аны буып, берничә урында бала-чага пычтырдарлык су җыялар. Без, малайлар, эссе көннәрдә шунда рәхәтләнәбез генә. Менә беркөнне, Тукаебыз әйтмешли, «бер сәгать ярым кадәрле уйнагач, инде шаять бер сәгатьсез тирләмәм дип уйлагач», судан чыктык та киенә башладык. Күрәбез: Салих Рафаэленең аркасында юылып төшмәгән ләм калган. Рафаэль исә күлмәген киеп маташа.

– Аркаңда пычрак бар, суга кереп, юып төшер, – дибез.

Ә ул, исе дә китмичә:

– Булса соң, ул төшне әти күрми лә, – диде дә, күлмәген тартып киеп тә куйды.

Кәнфит китергән шигырь

Билалетдин сүзгә бик оста, такмак чыгарырга һәвәс иде. Бервакыт, кибет тирәсендә сөйләшеп торганда, Эшбиттән кайткан авылдашыбыз аңа болай ди:

– Билалетдин, әгәр әтисенең һәм әнисенең исемнәре уртасына малайларының исемнәрен куеп, дүрт гаиләне бер шигырь белән әйтеп бирсәң, кибеттәге бер кило конфет синеке.

Малай шунда ук тезеп китә һәм конфетлы була.

Әлим, Зәйни, Мәхмүзә,
Пәси, Галим, Хәтирә,
Мостай, Шәриф, Мәчтүрә,
Пәез, Фәрзи, Тәскирә.

Плугар һәм печәгәр

1947–1948 нче елларда Арпаяздан берничә гаилә, төшемле эшкә өмет итеп, Бурят якларына күчеп китә. Елга якын вакыт узгач, Фәтхулла исемле абзыйдан авылга хат килеп төшә. Ул хат аша туганнарына, хатны укыганда тыңлап торучыларга сәламен язганнан соң, мондый фикерен җиткерә: «Үзебез Аллага шөкер, әйбәт кенә эшләп йөрибез, Насыйбулла – плугар, Гыйбадулла – печәгәр, беребез дә кара эштә түгел».

Ике ипи

Әтием Галимулла – тирә-якта бер дигән оста тимерче, бабам аны бу һөнәргә Югары Шөн дигән ар авылына Чтапан дәдәйгә йөртеп өйрәткән була. Эти күзәтә: Чтапан дәдәй, кешеләргә нәрсәдер эшләгәннән соң, бәяне шактый күп сорый. Эшләтүче кеше моның белән бәхәсләшә башлый: «Ә дигәнче эшләп куйдың да бик кыйммәт сорыйсың, ник алай?» «Эшләгәнем өчен бер ипи, ничек эшләргә кирәклеген белгәнем өчен ике ипи», – ди икән Чтапан дәдәй.

Күзлек аша күзәтү

Наданлык ул – мәгълүмат аз булудан, дип уйлый идек без элек. Аннары интернет барлыкка килде. Һәм без ничек ялгышканыбызны аңладык.

***

Көчле кешеләрне яратмыйлар. Алар уңайсыз. Алар белән идарә итеп булмый.

***

Сентябрь аенда бер ташкабак уртача 6 хуҗабикә кулыннан уза.

***

Ваннадагы күбекләр суның җылылыгын саклар өчен кирәк икән. Хәзер син барысын да беләсең!

***

Олы тормышка аяк баскач, шундый рәхәт икән! Бер эштән икенче эшкә барган арада, теләсә нәрсә эшлисең, үзең теләгәнчә яшисең.

***

Плутон планетасында җәй 40 ел дәвам итә. Бәрәңгене кайчан алалардыр?

***

Синоптиклар һава торышы фаразларында ялгышмый, көннәрдә генә ялгыша.

***

Бәдрәфтә бармакларыңны кул киптергечкә куйгач, ул эшләмәсә, уйла: бәлки, син бу дөньяда юктыр.

***

Кычытудан ярдәм итә торган кремыгыз беткән икән, савытын ташларга ашыкмагыз. Савытның кырые белән кашынырга бик уңайлы.

***

Кайбер кешеләр димломны бары тик кәгазь кисәге дип уйлый. Әмма акыллы кешеләр генә аның картон икәнен белә!

***

Ни өчен Казанда каһвә автоматлары адым саен, ә мәтрүшкәле чәй автоматы берәү дә юк?

Маймыл янында маймылланмагыз!

Фотога карагыз әле. Голландиянең Роттердам шәһәре зоопаркында кунакларга менә шушындый күзлек өләшәләр. Аны кигән кеше күзлектәге кечкенә генә тишек аша күрә. Ә рәсемдә – күзләр өскә карый. Бу ни өчен кирәк, дисезме? Чөнки гориллаларның күзенә туры карарга киңәш ителми икән. Әзмәвер маймыллар моны агрессия буларак кабул итә ди һәм ташланырга мөмкиннәр. Кызганыч, мондый очраклар булган.

2007 елның мае. Роттердам шәһәре. Зоопаркта Бокито кушаматлы 181 килограммлы «тәти» генә горилла яшәп ята. Ашый, эчә, нитә дигәндәй. Һәм берзаман бу маймылны карарга көн дә бер үк хатын-кыз – 57 яшьлек Ивонна де Хорд килеп йөри башлый. Көн саен күзгә-күз очраша болар. Хатын маймылга елмая. Тегесе дә моңа тешен ыржайта. Әмма күзгә-күз карашулы идиллия беркөнне бозыла. Бокито ике арадагы сулыкны йөзеп чыга да хатынга ташлана.

Баксаң, гориллалар гомумән елмаймый икән. Теш күрсәтү – алар өчен куркыту, янау билгесе. Теге хатынның мөлаем елмаюын да маймыл үзенчә кабул иткән. Ә инде күзгә туры карап тору… Анысы – бөтенләй дә гафу итмәслек нәрсә! Кыскасы, Бокито Ивоннаны шактый җәрәхәтләгән дә шәһәргә чыгып сызган. Әле бер ресторанга да кереп утырган соңыннан. «Гаҗәп инде бу кешеләр, – дип уйлый бугай маймыл, – үзләре зоопаркка мине карарга килә, ә үзем аларга килгәч, качалар». Күп тә үтми, җонлачны полиция хезмәткәрләре һәм зоопарк абый-апалары эзләп таба һәм махсус укол белән йоклаталар.

Шунысы кызык: бу хәлләрдән соң 57 яшьлек теге хатын зоопаркны судка бирмәкче була. Әмма бирми. Шәһәр халкы исә икегә бүленә. Кемдер хатынны яклый, кемдер маймылны. Бер караганда, теге хатын да явыз ният белән йөрмәгән бит инде, маймылга карата хәтта ниндидер җылы хисләре булган. Хәер, ир белән хатын арасына кермик, үзләре беләләрдер.

Шушы хәлдән соң Роттердам зоопаркында кагыйдәләр катгыйлана. Әлбәттә, кунакларны елмаюдан тыеп булмый. Елмаялар инде. Ә, кем әйтмешли, зрә! Ә менә күзгә-күз карашуларга әмәл тапканнар – сул як түшәмгә карый торган күзлекләр!

Карагыз әле, уйлап-уйлап торам да, хатыннан саклану өчен дә яхшы икән бит бу күзлек. Әйтик, хезмәт хакы алган көнне өйгә кайтып керәсең, ә хатының сиңа шундый иттереп карап тора! Туп-туры карый! Агрессия белән! Ә сиңа нәрсә? Син күзлектән. Ә күзләрең самими генә сул як түшәмгә карап тора.

vk.com

Сиражи «акыллылары»

Казанның икенче татар гимназиясендә актер, җырчы, журналист кебек иҗат әһелләренең балалары шактый укый. Беркөнне баласын каршы алырга журналист Искәндәр Сиражи да килгән. Улы Ирхан быел беренче сыйныфка барган икән. Сиражи булган җирдә шаян сүз булмый калмый. Бу юлы да кызыклы әңгәмә килеп чыкты.

– Беренчеләр дүрт класс дигәннәр иде, бу кайсылары чыгып килә икән?

– Бу «1А» чыгадыр. Акыллылар, – ди Сиражи.

– Ә «Б» нәрсә алайса?
– Бик акыллылар.
– Ә «1В»?
– Ваще акыллылар!
– Әле «1Г» да бар бит…
– Генийлар!

«Съешь же ещё этих мягких французских булок, да выпей чаю»

✓Бу җөмләгә рус алфавитында булган бөтен хәрефләр дә кергән.

✓Татар алфавитындагы бөтен хәрефләр кергән берәр җөмлә уйлап табыгыз әле.

Безгә җибәрсәгез дә була

Сәхифәне Данил СӘФӘРОВ әзерләде

ШУЛАЙ БЕРВАКЫТ «ТӘРТИП» РАДИОСЫНДА

Хатыйп Миңнегулов звонил

Берзаман «Тәртип» радиосы хезмәткәрләре Яшел Үзән районыннан кайтып килә. Каюм Насыйри эзләре буйлап экскурсия була бу. Машинада 5 кеше. Гадәттә, гел русча гына сөйләшүче тавыш режиссеры Алмаз Сәйфетдиновның телефоны шалтырый. «Алло! Исәнмесез! Әйе. Әле өлгермәдем. Беренче кисәге инде әзер, икенче кисәге әле әзер түгел. Яхшы. Сау булыгыз». Бу сүзләрдән соң машинадагы бөтен кеше Алмазга карый: «Алмаз, тукта әле, син татарча белмисең бит!» «Хатыйп Миңнегулов звонил», – ди Алмаз. «Ә-ә, алай булса аңлашыла, Хатыйп абый сөйләшмәс җиреңнән дә татарча сөйләштерә ул», – диләр.

Айгөл Нәбиуллина Принцны эзли

Айгөл Нәбиуллина радиода «Тәртипле иртә» тапшыруын алып бала. Айгөлнең һәрвакыт яхшы формада булуының сере бар. Ул чамалап кына ашый һәм көн саен берничә чакрым җәяү йөри. Кайвакыт аңа иптәшкә Принц кушаматлы эте дә иярә. Үзең генә йөргәндә уңайлырак, ди Айгөл, чөнки эте йә тегендә чаба, йә монда, бер тизлек белән генә йөрергә ирек бирми. Әле кайвакыт күпкатлы йортлар арасында адаша икән. Андый вакытта Айгөл аны кычкырып эзли башлый. Шуңа күрә, алдан ук кисәтеп куябыз: әгәр дә урамда Айгөл Нәбиуллинаның: «Принц! Принц!» – дип кычкырып йөргәнен күрсәгез, бер дә гаҗәпләнмәгез.

Ләйлә Ялалова һәм «стоматолог» Рәшит абый

«Тәртип» радиосының баш мөхәррир урынбасары Ләйлә Ялалованың эштә утырганда берзаман теше сызлый башлый. Ләйлә Рәшит исемле стоматологына шалтырата. Башта хәл-әхвәл сорашалар. Аннары төп мәсьәләгә күчелә: «Теш сызлый башлады бит әле, Рәшит абый». «Бер дә яхшы булмаган, – ди тегесе, – нишләп сызлый икән?» «Күрсәтергә кирәктер», – ди Ләйлә. «Әйе, күрсәтергә кирәк», – дип килешә әңгәмәдәш. Акыл теше авырта икән, Ләйлә моның барысын да бәйнә-бәйнә сөйли. Рәшит абый игътибар белән тыңлый, ничек тә хәлгә керергә тырыша. Нишләп алай булды икән, дип икәүләшеп баш кашыйлар. «Дәваларга кирәк инде моны, Рәшит абый», – ди Ләйлә. «Әйе-әйе, әбизәтелне!» «Сезгә кайчан килим соң дәваларга?» Бермәлгә тынлык урнаша. «Ләйлә, син кемгә шалтыратасың соң? Мин бит – Мөслимнән таксист Рәшит абыең». Шулай дигәч, икесе дә шаркылдап көләләр. Шулай да маладис Рәшит абый, Ләйләнең хәленә керергә тырышып, тешне үзе дәвалардай булган бит!

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 6708 данә
Гомуми тираж – 15890 данә

Газетага сертификат бирелде Заказ 336

РЕДАКЦИЯ һӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ

420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.

www.vatantat.ru

info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru

89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР

222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-73, 222-09-67 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы
222-09-67 – фән һәм мәгариф
222-09-64 – әдәбият, сәясәт һәм дин
222-09-66 – информация, спорт, тәрҗемә, оператор
222-09-67 – хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+